# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баланлы авыл җирлеге Чия–Түбә авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

25 ноябрь 2021 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2021елның 25 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2022 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлеге Чия–Түбә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 (жиде йоз) сум күләмендә**,** Бөек Ватан сугышы инвалидларыннан, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, Чернобыль һәлакәте инвалидларына 350 **(**өч йөз илле**)** сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

1. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү.
2. Халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру.

3. Физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыру.

4. Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештыру.

5. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру.

6. Җирлек чикләрендә урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү.

7. Каты коммуналь калдыкларны туплау һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу.

8. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту.

9. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны оештыру.

10. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге.

11. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 11 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 7, бу 64% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 5 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 2 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим униципаль районы Баланлы авыл җирлегенең Чия–Түбә авылында узган гражданнар нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлеге Чия–Түбә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700(жиде йоз) сум күләмендә**,** Бөек Ватан сугышы инвалидларыннан, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, Чернобыль һәлакәте инвалидларына 350 **(**өч йөз илле**)** сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү.
2. Халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру.

3. Физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыру.

4. Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештыру.

5. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру.

6. Җирлек чикләрендә урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү.

7. Каты коммуналь калдыкларны туплау һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу.

8. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту.

9. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны оештыру.

10. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге.

11. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру.

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Баланлы_авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Баланлы авыл җирлеге башлыгы Исламова И.И.